**Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында белдерү**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре Башкарма комитеты 2022 елның 27 сентябрендәге 48 номерлы күрсәтмәсе нигезендә түбәндәге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзү хокукына ачык аукцион үткәрү турында хәбәр итә:

| Лот номеры | Җир кишәрлегенең урнашу урыны, кадастр номеры | Кадастр номеры | Җир кишәрлеге милекчесе | Мәйданы, кв. м. | Җирләр категориясе | Рөхсәт ителгән куллану | Чикләүләр һәм йөкләмәләр турында мәгълүмат | Аренда вакыты | Еллык аренда түләвенең башлангыч күләме, сум | Аукцион адымы, сум | Задаток, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Производство ур. | 16:23:260231:104 | «Кукмара шәһәре» МБ | 37561 | торак пунктлар җирләре | җитештерү эшчәнлеге | Гавами кадастр картасы мәгълүматлары һәм ЕГРН нан өземтә нигезендә җир кишәрлегенең бер өлеше территорияне махсус куллану шартлары булган зонада урнашкан, шуның белән бәйле рәвештә җир кишәрлегенә Россия Федерациясе Җир кодексының 56, 56.1 статьяларында каралган чикләүләр (йөкләмәләр) бар. Җир кишәрлегенә карата сервитут яки ачык сервитут урнаштырылырга мөмкин | 5 ел | 603642,83 | 18109 | 120729 |

Аукцион 2022 елның 02 ноябрендә 14.00 сәгатьтә булачак. Адресы: ТР, Кукмара ш., Ленин ур., 15, 107 бүлмә.

Аукционда катнашу өчен гаризалар эш көннәрендә 2022 елның 30 сентябреннән 31 октябренә кадәр 08.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр кабул ителә. Төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр. Адресы: ТР, Кукмара ш., Ленин ур., 15, 1 кат, 109 бүлмә, белешмә өчен телефоны (84364) 2-65-00.

Аукционда катнашу өчен гариза билгеләнгән формада, задатокны кире кайтару өчен счет реквизитларын күрсәтеп, ике нөсхәдә төзелә. Гаризага кушымта итеп бирелә: гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документларның күчермәләре (гражданнар өчен); чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затның дәүләт теркәвенә алу турындагы документларының (гариза бирүче чит ил юридик заты булса) тиешенчә расланган рус теленә тәрҗемәсе; задаток кертүне раслый торган документлар. Задаток кертүне раслый торган документларны тапшыру задаток турында килешү төзүгә дип таныла. Тапшырыла торган документларның барлык битләре, шул исәптән гариза да тегелергә, номерланырга, гариза бирүче яисә вәкаләтле зат тарафыннан имзаланырга һәм гариза бирүченең мөһере белән беркетелергә тиеш. Гариза претендент вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта, тиешенчә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе тапшырыла.

Гариза бирүчегә түбәндәге нигезләр буенча аукционда катнашырга рөхсәт ителми:

1) аукционда катнашу өчен кирәкле документларны тапшырмау яки дөрес булмаган белешмәләр бирү;

2) аукционда катнашу өчен гаризаларны карау датасына задатокның бирелмәве;

3) аукционда катнашу өчен гариза Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә конкрет аукционда катнашучы булырга, конкрет җир кишәрлеген арендалаучы булырга хокуклы булмаган зат тарафыннан бирелгән;

4) гариза бирүче турында, гамәлгә куючылар (катнашучылар) турында, гариза бирүченең коллегиаль башкарма органнары әгъзалары, гариза бирүченең юридик зат булган аерым башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар турында белешмәләрнең аукционда намуссыз катнашучылар реестрында булуы.

Задаток кертү өчен хисап реквизитлары: Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы ( ЛР236390485-пгтКукИК), ИНН 1623008271, КПП 162301001,
акча алучы хисабы: 03232643926331011100 Россия Банкының Татарстан Республикасы Милли банкы бүлеге / Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре, БИК 019205400 алучы банкы хисабы 40102810445370000079. Гаризалар кабул итү вакыты чыкканнан соң килгән аукционда катнашу өчен гариза кергән көнендә гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Гариза бирүче аукционны оештыручы тарафыннан кабул ителгән аукционда катнашу өчен гаризаны, гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганчы, бу турыда аукционны оештыручыга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы. Аукционны оештыручы гариза бирүчегә ул керткән задатокны гаризаны кире алу турында хәбәрнамә кергән көннән өч эш көне эчендә кире кайтара. Гаризаны гариза бирүче гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң кире алган очракта, задаток аукционда катнашучылар өчен билгеләнгән тәртиптә кире кайтарыла. Аукционны оештыручы аукцион үткәрүдән гаризалар кабул итүнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча баш тартырга хокуклы.

Гаризаларны карау 2022 елның 01 ноябрендә 13.00 сәгатьтә булачак. Адресы: ТР, Кукмара ш., Ленин ур., 15, 1 кат, 107 бүлмә Аукционда катнашучылар дип танылган яки аукционда катнашуга кертелмәгән гариза бирүчеләргә, аукционда катнашу өчен гаризалар каралганнан соң икенче көннән дә соңга калмыйча, кабул ителгән карар турында хәбәр ителә. Аукционда катнашуга кертелмәгән гариза бирүчеләргә задаток гаризаларны карау беркетмәсен тутырганнан соң өч эш көне эчендә кире кайтарыла.

Аукционның җиңүчесе дип җир кишәрлеге өчен иң зур күләмдә еллык аренда түләве тәкъдим иткән аукционда катнашучы таныла. Аукцион үткәрү көнендә ТР, Кукмара ш., Ленин ур., 15 йорт, 1 кат, каб.107 адресында аукцион нәтиҗәләре турында ике нөсхәдә беркетмә төзелә, шуларның берсе аукцион җиңүчесенә тапшырыла, ә икенчесе аукционны оештыручыда кала. Аренда шартнамәсе төзелгән зат тарафыннан кертелгән задаток аның өчен аренда түләве хисабына исәпләнә. Аукционда катнашкан, әмма анда җиңмәгән затларга задатоклар аукцион нәтиҗәләре турында беркетмәгә кул куелганнан соң өч эш көне эчендә кире кайтарыла.

Аукцион тормышка ашмаган дип таныла:

а) Әгәр аукционда катнашу өчен гаризаларны карау нәтиҗәләре нигезендә барлык гариза бирүчеләрне аукционда катнашуга кертүдән баш тарту яки бары тик бер генә гариза бирүчегә аукционда катнашырга рөхсәт бирү һәм аукционда катнашучы дип тану турында карар кабул ителсә;

б) әгәр аукционда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң, аукционда катнашуга бары тик бер генә гариза бирелгән яки аукционда катнашуга бер генә гариза да бирелмәгән булса.

Югарыда санап үтелгән очракларда, гариза бирүченең һәм аның гаризасының аукцион шартларында билгеләнгән таләпләргә һәм аукцион шартларына туры килүе шартында, вәкаләтле орган аукционда катнашу өчен гаризаларны карау беркетмәсенә кул куйганнан соң ун көн эчендә гариза бирүчегә җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проектының имза салынган өч нөсхәсен җибәрә. Шул ук вакытта аренда шартнамәсе аукцион предметының башлангыч бәясе буенча төзелә.

в) Әгәр аукционда бары тик бер катнашучы катнашкан булса яки аукцион үткәргәндә аукционда катнашучыларның берсе дә катнашмаган булса, яки аукцион предметының башлангыч бәясе турында өч тапкыр тәкъдим белдерелгәннән соң, аукцион предметының бәясе турында аукцион предметының тагын да югарырак бәясен күздә тоткан бер генә тәкъдим дә кертелмәгән булса. Бу очракта вәкаләтле орган аукцион җиңүчесенә яки аукционда катнашкан бердәнбер катнашучыга аукцион нәтиҗәләре турында беркетмә төзелгән көннән соң ун көн эчендә аренда шартнамәсе проектының өч нөсхәсен җибәрә. Шул ук вакытта җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе аукционда җиңүче тәкъдим иткән бәядән яки, әлеге шартнамә аукционда катнашкан бердәнбер катнашучы белән төзелгән булса, аукцион предметының башлангыч бәясе буенча төзелә.

Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүматны рәсми сайттда урнаштырганнан соң кимендә ун көннән төзелә.

Әгәр аукционда җиңүчегә (бердәнбер гариза бирүчегә, аукционның бердәнбер катнашучысына) җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты җибәрелгәннән соң утыз көн эчендә күрсәтелгән шартнамәгә аның тарафыннан кул куелмаса һәм вәкаләтле органга тапшырылмаса, задаток мондый затка кире кайтарылмый.

Әгәр җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе аукционда җиңүчегә күрсәтелгән шартнамә проекты җибәрелгәннән соң утыз көн эчендә аның тарафыннан имзаланмаса һәм вәкаләтле органга тапшырылмаса, аукционны оештыручы аукцион предметының бәясе турында аукционда җиңүче тәкъдим иткән бәядән соңгыдан алда тәкъдим ясаган аукцион катнашучысына аренда шартнамәсе төзергә тәкъдим итә. Аукцион предметының бәясе турында соңгыдан алда тәкъдим ясаган аукцион катнашучысына җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты җибәрелгән көннән соң утыз көн эчендә бу катнашучы вәкаләтле органга кул куелган шартнамәне тапшырмаса, аукционны оештыручы кабат аукцион үткәрү турында игълан итәргә яки җир кишәрлеге белән Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә бүтәнчә эш итәргә хокуклы.

Тулырак мәгълүмат алырга, гариза формасы, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе проекты белән гаризаларны кабул итү урынында һәм «www.torgi.gov.ru» һәм «www.kukmor.tatarstan.ru. сайтларында танышырга мөмкин.

ЕГРН нан өземтәдәге җир кишәрлегенең урнашу урыны тасвирламасы буенча җир кишәрлеге чикләре.

Урынга барып җир кишәрлеген карау гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, теләсә кайсы вакытта башкарыла.

* Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең 2012 елның 12 июлендәге 14 номерлы карары (2016 елның 30 сентябрендәге 26 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы нигезендә, 16:23:260231:104 кадастр номерлы Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара ш., Производство урамы адресындагы җир кишәрлекләре ПК-1 куркынычлылык V классындагы җитештерү-коммуналь объектлар зонасына керә, аның өчен рөхсәт ителгән файдалануның түбәндәге төрләре каралган:

Рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре:

- төрле профильдәге V куркынычлык классындагы коммуналь-склад һәм җитештерү предприятиеләре;
- бокс тибындагы гаражлар, аерым җир кишәрлегендә күп катлы, җир асты һәм җир өсте гаражлары, автомобиль кую урыннары;
- җиңел автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү станцияләре 5 постка кадәр (маляр-калай эшләреннән тыш);
- предприятиеләрне техник һәм инженерлык тәэмин итү объектлары;
- санитар-техник корылмалар һәм коммуналь билгеләнештәге җайланмалар;
- офислар, конторалар, административ хезмәтләр;
- проект, фәнни-тикшеренү, конструкторлык һәм тикшеренү оешмалары һәм лабораторияләре;

- күпләп сату, ваклап сату сәүдә предприятиеләре һәм үзләре җитештергән товар- ларны сату буенча ваклап сату кибетләре;
- полиция бүлекләре, участок пунктлары;
- янгыннан саклау объектлары, янгын частьләре.

Рөхсәт ителгән файдалануның ярдәмче төрләре:

- кыска вакытлы автомобильләр саклау урыннары, автобуслар, йөк автомобильләре, җиңел автомобильләр саклау урыннары булган транзит транспорты мәйданчыклары.

Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төрләре:

- җитештерү һәм сәнәгать предприятиеләренә турыдан-туры хезмәт күрсәтү белән бәйле җәмәгать туклануы предприятиеләре (кафе, ашханә, буфетлар);
- предприятиеләргә хезмәт күрсәтү белән бәйле идарә биналары, конструкторлык бюролары, сырхауханәләр, фәнни-тикшеренү лабораторияләре;
- предприятие хезмәткәрләре өчен ябык типтагы спорт-сәламәтләндерү корылмалары;
- киосклар, лотоклы сәүдә, ваклап сату һәм халыкка хезмәт күрсәтү буенча вакытлыча павильоннар;
- сәнәгать товарлары базарлары;
- аерым тора торган Эчке эшләр идарәсе, район эчке эшләр бүлеге, ЮХИДИ бүлекләре, хәрби комиссариатлар;
- ветеринария дәваханәсе, ветеринария кабул итү пунктлары;
- җиңел автотранспортка сыек ягулык салу өчен генә күп дигәндә 3 ТРК лы автозаправка станцияләре, шул исәптән хезмәт күрсәтү объектлары белән;
- беренче медицина ярдәме күрсәтү пунктлары;
- аерым тора торган көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары;
- сәнәгать территорияләрен һәм санитар-яклау зоналарын яшелләндерү өчен үсемлекләр питомниклары;
- кәрәзле, радиорелелы, спутник элемтәсе антеннасы;
- вахта методы буенча (күп дигәндә ике атна) эшләүчеләр өчен бүлмәләр.